**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 07 2021 № 242

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧ профилактикасы һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 01.07.2021 ел, №209 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧ профилактикасы һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 01.07.2021 ел, №209 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турында» 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссиянең персональ составы һәм аның Рәисе Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә шәхсән катнашалар.».

1.2 9 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты финанс
һәм мөлкәт белән идарә итү буенча
җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Муратшин